ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2019 г. Заинск № 479

**«Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 1162 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектлары өчен трассаны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип тану хакында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 29 декабрендәге 2901 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» гы карары, Зәй муниципаль районы Уставының 45 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 1162 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектлары өчен трассаны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары үз көчен югалткан дип танырга (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 декабрендәге 1808 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары М.И.Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Р.Р. Исламова
3-47-87